КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 апрель г.Казань № 226

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы; 2022 ел, 2 август, 751 нче; 2022 ел, 27 август, 916 нчы; 2022 ел, 17 сентябрь, 1013 нче, 2024 ел, 29 апрель, 287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2025 елның 1 маеннан арттырырга.

2. Бу карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен муниципаль берәмлекләрдә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладны күләмен 1,1 тапкырга индексацияләргә һәм аның күләмен 15 389 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче, 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы, 2022 ел, 2 август, 751 нче, 2022 ел, 27 август, 916 нчы, 2022 ел, 17 сентябрь, 1013 нче, 2024 ел, 29 апрель, 287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «37 проценты» сүзләрен «52 проценты» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 4 пунктчасында «37 проценты» сүзләрен «52 проценты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Кайбер оешмалар җитәкчеләренә элегрәк чыгарылган актларын бу карарга туры китерергә.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин